## БЕРЕНЧЕ СӘНГАТЬ ЧАТКЫЛАРЫ

Бөтен дөньяга сибелеп яшәгән татар халкы 18нче гасыр урталарында Казахстан шәһәрләренә күпләп күченеп килә башлый. Алар корал күтәреп килмиләр, китап күтәреп киләләр. Казахстанга – элекке Верный шәһәренә – татар меценатлары Исхак Габделвәлиев, Зәйнетдин Таҗетдиновлар күчеп килеп, төпләнеп яши башлыйлар.

1нче гильдияле татар сәүдәгәре Габделвәлиев, сүәдә йорты салып, Кытай белән сәүдә итә башлый. Алар Верный шәһәрендә мәчет, мәдрәсәләр, китапханә салалар. Исхак Габделвәлиев салган кафедраль мәчет бинасында 1920нче елларда “Гаспринский” исемендә 9 еллык татар мәктәбе эшли башлый.”Дворянское собрание” бинасында профессор Исмагилов Галиәсгар Камалның “Беренче театр” дигән әсәрен сәхнәгә куя.

1919-1920нче елларда артист Х.Уразиков “Театр Тукая” исемле татар театры оештыра. Әмма 1930-1936нчы елларда аларның барысын “халык дошманы” дип хөкем чыгарып, юк итәләр. Казахстанның төрле шәһәрләрендә татар сәүдәгәрләре-меценатлары, алдынгы фикерле зыялылары сәнгатькә, белемгә, дини яктан белемле булуга нигез салалар. Безнең ата-бабаларыбыз милләт киләчәген уйлап кылган изге гамәлләрен киләсе буыннарга мирас итеп калдырганнар. Кызганычка каршы, бик күп еллар Верный (хәзерге Алматы) шәһәрендә төпләнеп яшәгән, күп санлы Казахстан Республикасының үсешенә зур хезмәт күрсәткән, бу якларда белем, сәнгать учакларын кабызган татар халкы музыкасыннан, сәнгатеннән, тирә-якны иман нуры белән нурландырган мәчетеннән мәхрүм булып яши.

Ниһаять, 1966-1967 елларда Татарстаннан керәшен егете Майоров Владимир Константинович, җырчы, гармонист-виртуоз Мәсхүт Гыйләҗев, Минзәлә татар драма театры артисты мин, Равил Гозәиров, Алматы шәһәрендәге “Офицерлар йортының” директоры майор Шевяков Владимир Степанович ярдәмендә, “Яшьлек” исемле татар ансамбле оештырып, концертлар куя башлыйлар. Ансамбльнең беренче сандугачлары – П.И.Чайковский исемендәге музыка училищесе 1нче курс студенткасы Галибә Сайбулатова, табигатьтә сирәк очраган моңлы тавышлы Фирдәүс Сафаргалиевалар – моңга сусаган тамашачыларны хәйран калдырып, аларның йөрәкләрендә хисләр уяталар.

“Яшьлек” ансамбле кыска гына вакыт арасында халык яраткан үзенчәлекле ансамбльгә әйләнә. Концертлары аншлаг белән бара. Кызганычка каршы, халыкара бердәмлек булмау сәбәпле, күрәлмәүчеләрнең аяк чалулары аркасында ансамбль таралырга мәҗбүр була.

Тик 1985нче елның октябрь аенда казах журналисты, музыка сөюче Серик Калиевның ярдәме белән Алматы Мөгаллимнәр

йортында талантлы композитор, оста гармунчы, концертмейстер Галимҗан Тамендаров, Галибә Сайбулатова, Фирдәүс Сафаргалиева, оста баянчы, музыка белгече Халит Закирович Галиакберов, Казан егете баянчы Тәлгать Сәйфуллин, гармунчы Шәүкәт Сәхәүтдинов, җырчылар Заһит Шакиров, Нәкия Вафина, Роза Ишкенова, Флүр Мухиянов, Ләбибә Сермухамедова, үзе берничә гармунда уйнап җырлаучы Әхтәм Шайбаков, җырчы, нәфис сүз остасы Шамил Сәхәүтдинов, баянчы Шәхдәт Чимбарисов, биючеләр Энҗе, Радмила һәм Регина Гозәировалар, хореограф Зөһрә Мәҗитова, биючеләр Альбина һәм Нелли Вайсман, курайчы Нурахмет Ңорабеков, җырчы Хәмидә Галиакберова һ.б. ансамбль оештырып, репетицияләрен башлыйлар.

Ансамбльгә “Сарман” дип исем бирәләр. Ансамльнең музыка җитәкчесе итеп Халит Галиакберов, сәнгать җитәкчесе итеп бер тавыштан Равил Гозәиров сайланалар. Шәриф Усманов, Ибраһим Хисамутдинов, Серик Калиевның тырышлыгы аркасында ЦК компартии Казахстана басмаханәсе “Полиграфист” мәдәният йорты директоры Нугманова Гульнара Хамзиновна белән килешеп, шушы мәдәният йортында төпләнеп эшләргә урын бирәләр.

Кыска гына вакыт арасында концертлардан концертларга “Сарманның” абруе күтәрелеп, халыкның яраткан ансамбленә әйләнә. Концерт беткәч тә тамашачылар, аяк өсте басып торып, озак кул чабып: “Рәхмәт сезгә, сарманлылар, сезнең концертларыгызны караганнан соң без үзебезне чын татар икәнебезне хис итеп, канатланып яши башладык!” – дип китәселәре килмичә торалар. Сәхнә түренә чыгып, микрофон алып, “Сарманга” уңышлар теләп, кат-кат рәхмәт әйтәләр.

1989нчы елның февраль аенда Ибраһим Хисаметдинов белән мине Казанга, татар-иҗтимагый үзәген кору корылтаена делегат итеп чакыралар. Профессор Марат Мулюков делегатларны үзе каршы ала. Корылтайның эш тәртибендә башка төбәкләрдә яшәгән татарларның мәдәни үзәкләрен оештыру мәсьәләсе карала. Киткәндә оештыру тәртипләре белән таныштырып, методик брошюралар биреп җибәрәләр.

Кайту белән җыелышта “Сарман” әгъзалары нигезендә (30-40 кеше) үзәк кору турысында карар кабул ителә. Үзәкнең уставын язуда югары белемле юрист Алһамов Наил зур ярдәм күрсәтә. “Сарман” үзенең эшен дәвам итеп, зур уңышларга ирешә, өч мәртәбә татар халык ансамбле исеменә лаек була. 1993нче елны, “үзгәртеп кору” башлангач, “Полиграфисттан” чыгарылып, татар мәдәни үзәге карамагына күчеп, урынсыз калса да, үзенең эшен дәвам итә.

1996нчы елда 10 еллык юбилей концертын биреп, бар халыкны таң калдыра. 1998нче елда Төркиядә фестивальдә катнашып, лауреат булып кайта.

Татарский народный ансамбль «Сарман» внёс огромный вклад в развитие культурной жизни Республики Казахстан. Заслуженный работник Республики Татарстан Галиба Сайбулатова более 30 лет проработала в «Казахконцерте», исполняя песни на казахском, татарском, русском и других языках. Галимжан Тамендаров – музыкальный руководитель ансамбля «Сарман», композитор, талантливый музыкант – своими музыкальными произведениями обогатил не только репертуар ансамбля «Сарман», но и других ансамблей Республики Казахстан. Известная хореограф Камария Мансурова – отличник народного образования Республики Казахстан, с 1970 г. бессменный руководитель детского образцово-показательного ансамбля «Ак Маржан». Они исполняют танцы народов мира, дипломанты международных конкурсов.

Гриф Тимурзагитович Хайруллин – доктор педагогических наук, профессор, издал несколько книг по истории татар, вложил большой труд в издание энциклопедического словаря «Татары в Казахстане».

Зухра Мажитова – кандидат педагогических наук, хореограф, ставит характерные темпераментные танцы. Украсила концертную программу, обогащая репертуар ансамбля.

Мы благодарны казахскому народу за гостеприимство. В трудные годы мы нашли здесь свою вторую родину и внесли вклад в развитие современного Казахстана.

Вот стихотворение о дружбе наших народов, которое я написал на казахском языке:

**ТАТАР-ҚАЗАҚ ДОСТЫҒЫ**

Татар менен қазағым
Құда болған бұрыннан.
Жүрген олар келіп-кетіп,
Кездескенде сөз бітпеген,
Әңгіме құрып, өлең айтып.

Татар менен қазағым,
Екеуі де затты халық,
Тарихы бай данлы халық,
Тілі менен тәтті халық,
Бар нәрсеге хақты халық!

*Заслуженный работник культуры Республики Татарстан,*
*Член союза писателей Республики Татарстан,*
*Художественный руководитель ансамбля «Сарман»*
*Равиль Гузаиров*